ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында” 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кушымтасына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «10 | Автомобиль транспортында йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 270 | 3 000 | 600 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «10 | Автомобиль транспортында йөкләр ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 600 | 3 000 | 600 | 5 000»; |

2)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.1 | Такси эшчәнлеге | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 500 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.1 | Такси эшчәнлеге | транспорт чарасы | 500 | 3 000 | 500 | 5 000»; |

3)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.2 | Пассажирлар йөртү буенча, такси эшчәнлегеннән тыш, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 800 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «11.2 | Пассажирлар йөртү буенча, такси эшчәнлегеннән тыш, автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 800 | 3 000 | 1 800 | 5 000»; |

4)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «33 | Су транспортында йөк ташу хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 250 | 3 000 | 1 000 | 5 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «33 | Су транспортында йөк ташу хезмәтләре күрсәтү | транспорт чарасы | 1 000 | 3 000 | 1 000 | 5 000»; |

5)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000» |

юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе | | | | | » |

һәм аннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «46.1 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе (таратыла торган ваклап сату сәүдәсеннән тыш) | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 3 450 | 10 000 |
| 46.2 | Сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату сәүдәсе (таратыла торган ваклап сату сәүдәсе өлешендә) | сәүдә челтәре объекты | 2 500 | 10 000 | 2 500 | 10 000»; |

б)

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «47 | Җәмәгать туклануы оешмасының һәр объекты буенча кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы 50 квадрат метрдан артыграк булмаган мәйданлы җәмәгать туклануы оешмасы объектлары аша | җәмәгать туклануы оешмасы объекты | 1 200 | 10 000 | 1 950 | 10 000» |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | | | | | |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «48 | Кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы булмаган җәмәгать туклануы оешмасы объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы буенча хезмәт күрсәтүләр | җәмәгать туклануы оешмасы объекты | 1 000 | 1 000 | 1 950 | 5 000 |
| 49 | Терлек сую, транспортировкалау, куып алып бару, көтү буенча хезмәт күрсәтүләр | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 50 | Күн һәм күн әйберләр җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 51 | Ашарга ярый торган урман ресурсларын, агач булмаган урман ресурсларын һәм дару үләннәрен җыю һәм әзерләү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 52 | Җиләк-җимеш һәм яшелчәләрне киптерү, эшкәртү һәм консервлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 53 | Сөт продукциясе җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 54 | Җиләк-җимеш үсентесе материалларын җитештерү, яшелчә культуралары үсентеләре һәм үлән | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | орлыклары үстерү | | | | | |
| 55 | Икмәк һәм камыр ашы кондитерлык әйберләре җитештерү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 56 | Товар һәм спорт балыкчылыгы һәм балык үрчетү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 57 | Урманчылык тармагы һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 58 | Язма һәм телдән тәрҗемә эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 59 | Өлкәннәрне һәм инвалидларны карау эшчәнлеге | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 310 | 5 000 |
| 60 | Калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү, шулай ук икенчел чималны эшкәртү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 61 | Һәйкәлләр өчен таш кисү, эшкәртү һәм бизәү | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |
| 62 | ЭВМ һәм белешмәләр базасы (исәпләү техникасының программа чаралары һәм мәгълүмат продуктлары) өчен программалар эшләү буенча хезмәт күрсәтүләр (эшләр башкару), аларны яраклаштыру һәм | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | модификацияләү | | | | | |
| 63 | Компьютерлар һәм коммуникация җайланмаларын ремонтлау | индивидуаль эшкуарны кертеп, эшләүчеләр саны | 310 | 1 000 | 370 | 5 000». |

**2 статья**

Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 19 ноябре
№ 95-ТРЗ